**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»**

Переулок Больничный, дом 6,
пгт. Рыбная Слобода, 422650

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**«МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

Хастаханә тыкрыгы, 6 нчы йорт,
Балык Бистәсе штп., 422650

Тел.: (8-84361) 2-21-92, факс: (8-84361) 2-21-26. E-mail: sloboda.ege@rambler.ru, sloboda.filial@mail.ru

---

**Балык Бистәсе муниципаль районы “ Балык бистәсе 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызының педагогик эшчәнлегенә бәяләмә**

Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызы беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Педагогик стажы 22 ел. Ул иҗади шәхес, талантлы укытучы, үз фәнен һәм эшен яратып башкаручы остаз. Рәзилә Нурмый кызын хезмәттәшләре һәр эшне җиренә җиткереп, иҗади якын килеп башкаруы өчен яраталар. Ул бик зур оештыру сәләтенә ия, һәрвакыт яңалыкка омтыла һәм укучылардан да шуны таләп итә.

Аның иҗади эшчәнлеге сәләтле укучыларына зур уңышларга ирешергә мөмкинлек бирә. Район, бөтенрәсәй һәм республикакүләм бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә, район күләмендә татар теле һәм әдәбиятыннан уткәрелгән олимпиадаларда төрле призлы урыннар яулыйлар. Соңгы 3 елда гына да укучылары белән дистәгә якын призлы урыннар яуланган. Укытучының олимпиадаларга әзерләү буенча зур тәҗрибәсе бар. Укучыларының белемнәре тотрыклы, шуның нәтиҗәсе буларак, укучылары туган телдән республика олимпиадасының муниципаль турында һәр елны җиңүчеләр рәтендә.

Рәзилә Нурмый кызы мәктәп тормышында, иҗтимагый эшләрдә актив катнаша, һәр биремне төгәл, вакытында һәм җиренә җиткереп утәргә ярата. Булдыра алмам дип куркып тормый, һәр эшкә кыю алына һәм нәтиҗәле итеп башкарып чыга. Укытучы һәрбер дәресендә укучыларына иҗади якын килергә, күңелләренә матурлык орлыклары салып эшләргә тырыша. Матурлыкны ул - туган телебездә, милли йолаларда , татар халкының яшәешендә, халкыбызның иҗади шәхесләрендә күрә. Күп кенә ачык дәресләр үткәрә. Үткәргән ачык дәресләре югары бәяләнә. Сыйныфтан тыш чараларга аерым игътибар итә. Мәктәптә иҗади түгәрәк җитәкли. Түгәрәккә йөрүче укучылары һәр бәйрәмдә уңышлы чыгыш ясыйлар, туган телебезнең милли аһәңен укучыларыбызга, укытучыларыбызга, килгән кунаклар күңеленә дә иңдерергә тырышалар. Аларның чыгышларын яратып күзәтәләр, алкышларга күмәләр. Укучысы Гаффарова Руфинә, Рафаил Газиз исемендәге төбәкара әдәби бәйгедә катнашып, III урынга лаек булды һәм Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Бу күрсәткеч тә укытучы хезмәтенең нәтиҗәсе булып тора. Ул укучыларын да иҗатка дәртләндерә, үзе дә шигырьләр иҗат итә. Татарстан

Республикасы Мәгариф министрлыгы оештырган “Илһам чишмәсе” исемле республика-иҗади бәйгедә катнашып III дәрәҗәле дипломга лаек булды.
Укытучы үз белемен күтәрү өстендә даими эшли. Эш тәҗрибәсен теләп уртаклаша, үзенең эш тәҗрибәсе турында педагогик укуларда, район татар теле укытучыларының утырышларында даими чыгыш ясый. Иҗади группа утырышларында үзенең фикерләрен әйтә, дәресләр анализлауда актив катнаша. Даими рәвештә ачык дәресләр бирә. Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызы ирешкәннәре белән генә тукталып калмый,тәҗрибәле укытучыларның дәресләрендә дә була, фән укытудагы яңалыклар белән танышып бара.

Рәзилә Нурмый кызы - 5 сыйныф җитәкчесе дә. Укытучының һәрбер башлангычка җаваплы каравы, укучыларын яратуы, төпле белем һәм тәрбия бирүе укучылар һәм ата- аналар арасында зур игътирамга лаек .

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының “Мәгариф
бүлеге “ муниципаль казна
учреждениесе җитәкчесе И.М.Садыйков